СОВЕТ ОКТЯБРЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ОКТЯБРЬСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ — КАРАР

27.07.2018 — пос. Октябрьский — 44-190

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының
Октябрьский авыл җирлеге Уставы проекты турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль закон, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Татарстан Республикасы Законы, Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Советының2013 елның 17 апрелендәге 29-144 номерлы карары белән расланган Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районының
Октябрьский авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Уставы проектын беренче укылышта кабул итәргә һәм аның өстендә тәкъдимнәр, төзәтмәләр һәм искәрмәләр исәпкә алып эшләүне дәвам итәргә тәкъдим итте (1 нче кушымта).
2. Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Уставы проекты буенча түбәндәге составта тәкъдимнәр кабул итү, исәпкә алу һәм карау буенча эшче төркем төзергә:
   Эшче төркем әгъзалары:

- эш төркеме рәисе, Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге башлыгы Азизов Ш.Р.;
- эш төркеме секретаре, Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Башкарма комитеты секретаре Янгуразова А.Р.;
- Октябрьский авыл җирлеге Советының 5 нче Яңа Болгар сайлау округы буенча депутаты Нефедов В.А.

- "Октябрьский  урта гомуми белем бирү мәктәбе" МБОУ  директоры Назаров А.С.
- Октябрьский авыл җирлеге ветераннар оешмасы Советы рәисе Ибраһимова К.Х.

3. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Уставы проектына гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен расларга. (2 нче кушымта).

4. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Уставы проекты буенча фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибен расларга. (3 нче кушымта).

5. Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Уставы  проекты буенча  гавами тыңлауларны 2018 елның 16 августы  10.00 сәгатьтә Октябрьский авылы Мәдәният йортында , ТР, Югары Ослан районы, Октябрьский ав., Үзәк ур., 7 й. адресы буенча уздырырга.

6. Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлегендә яшәүчеләрнеӊ кергән тәкъдимнәрен гомумиләштерергә һәм аларны Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Советы каравына кертергә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

8. Әлеге Карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Советының социаль-мәдәни, законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Октябрьский авыл җирлеге башлыгы Ш. Р. Азизов